**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**12 май 2022 ел** **№18-09**

«Актаныш муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесенең 2021 елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында

«Актаныш муниципаль районы контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе рәисе М.М.Яинованың 2021 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында «Актаныш муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль казна учреждениесе хисабы хакында фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 февралендәге 6-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең аерым контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең аерым мәсьәләләре турында» 2012 елның 17 маендагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, «Актаныш муниципаль районының контроль-хисап палатасы турында»гы нигезләмә нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. «Актаныш муниципаль районының контроль-хисап палатасы» муниципаль учреждениесенең 2021 елдагы эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисабын игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).
2. Актаныш муниципаль районының контроль-хисап палатасына район бюджеты үтәлешенә тышкы финанс контролен гамәлгә ашыруга, район бюджетының аерым бүлекләре һәм статьялары буенча контроль фукцияләрне башкаруга, муниципаль милектәге мөлкәт белән идарә итүнең һәм эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүгә һәм муниципаль сатып алуларның нәтиҗәлелегенә аудит ясауга юнәлтелгән эшне дәвам итәргә.
3. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы
Советы рәисе Э.Н.Фәттахов